| | |
|---|---|
| МЭР ГОРОДА<br>НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>ХАКИМЕ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 гыйнвар 2026 ел №М 22

«Яр Чаллы шәһәренә 400 ел»
юбилей истәлек билгесен
гамәлгә кую турында

Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгын бәйрәм итү уңаеннан, шәһәр үсешенә әһәмиятле өлеш керткән гражданнарның аерым казанышларын тану максатында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Яр Чаллы шәһәренә 400 ел» юбилей истәлек билгесен гамәлгә куярга.

2. Расларга:

1) «Яр Чаллы шәһәренә 400 ел» юбилей истәлек билгесе турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Яр Чаллы шәһәренә 400 ел» юбилей истәлек билгесен тапшыру турында юлламаларны карап тикшерү буенча комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2026 елның 28 гыйнварындагы
М 22 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәренә 400 ел» юбилей истәлек билгесе турында
нигезләмә

1. бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Яр Чаллы шәһәренә 400 ел» юбилей истәлек билгесе (алга таба — Истәлек билгесе) Яр Чаллы шәһәренә нигез салынуның 400 еллыгы хөрмәтенә гамәлгә куелды һәм ул шәһәр бүләге булып саналмый.

2. «Яр Чаллы шәһәренә 400 ел» юбилей истәлек билгесе турында әлеге нигезләмә (алга таба — Нигезләмә) «Яр Чаллы шәһәренә 400 ел» юбилей истәлек билгесен тапшыру шартларын һәм тәртибен билгели.

3. Истәлек билгесе Яр Чаллы шәһәре иминлеген, анда яшәүчеләрнең мул тормышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекләре өчен, һөнәри өлкәдә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә икътисадый үсешкә, җитештерүне, фәнне, мәдәниятне, мәгарифне, сәламәтлек саклауны, спортны үстерүгә, хокук тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын ныгытуга юнәлдерелгән югары казанышлары өчен, Яр Чаллы шәһәре үсешенә зур өлеш керткән затларга, Яр Чаллы шәһәрендә үткәрелә торган бәйрәм чараларына чакырылган шәһәрнең мактаулы кунакларына тапшырыла.

4. Истәлек билгесен тапшыру, Истәлек билгесен тапшыру турындагы юлламаны карап тикшерү буенча комиссия карарын исәпкә алып, Яр Чаллы шәһәре Хакиме тарафыннан расланган Истәлек билгесен тапшыру өчен гражданнар исемлеге нигезендә башкарыла.

5. Истәлек билгесен кабат тапшыру рөхсәт ителми. Истәлек билгесен югалтканда дубликат бирелми. Истәлек билгесе тапшырылган затларны исәпкә алуны шәһәр Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

6. Истәлек билгесен ясатуны оештыруны Башкарма комитет гамәлгә ашыра.

7. Истәлек билгесен ясатуны оештыруны финанслау Яр Чаллы шәһәре бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

2 бүлек. Истәлек билгесен тапшыру нигезләре һәм тәртибе

8. Истәлек билгесен тапшыру турында юллама Яр Чаллы шәһәре Хакиме исеменә 2026 елның 2 февраленнән 2026 елның 30 декабренә кадәрге чорда Яр Чаллы шәһәре үсешенә керткән конкрет өлешен күрсәтеп (казанышларын тасвирлап), уңышларын һәм казанышларын раслый торган документларның тиешенчә таныкланган күчермәләрен теркәп, Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, дәүләт хакимиятенең территориаль органнары җитәкчеләре, оешмалар җитәкчеләре тарафыннан җибәрелә.

9. Истәлек билгесен тапшыру турында юллама органнар (оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләр) җитәкчеләре тарафыннан әлеге Нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча җибәрелә.

10. Юлламаларны теркәү Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты канцеляриясендә гамәлгә ашырыла.

11. Әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән документларның сыйфатсыз әзерләнүе һәм (яки) тапшырылмавы, юлламаны канәгатьләндерүдән баш тарту өчен нигез

булып тора.

12. Истәлек билгесен тапшыру турында юлламаны карап тикшерү өчен составы әлеге карарга 2 нче кушымтада расланган комиссия төзелә.

13. Комиссия рәисе (алга таба — рәис) эшне оештыруны тәэмин итә, утырышның датасын билгели. Рәиснең үз бурычларын үтәү мөмкинлеге булмаган очракта, аның функцияләрен рәис урынбасары үти.

14. Комиссия секретаре комиссия әгъзаларына утырышны үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр итүне тәэмин итә, беркетмә рәсмиләштерә, рәиснең комиссия эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле йөкләмәләрен үти. Секретарь булмаган очракта, рәис кушуы буенча аның функцияләрен комиссия әгъзаларының берсе үти.

15. Комиссия утырышлары, алар теркәлгән көннән башлап бер ай эчендә карап тикшерелә торган юлламалар кергән саен үткәрелә.

Комиссия утырышы, составының кимендә өчтән ике өлеше катнашканда, тулы хокуклы дип санала. Карар утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. «Риза» һәм «каршы» тавышлары тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

16. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, рәис, секретарь, комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

17. Комиссия карары Истәлек билгесен тапшыруга кандидатларны Яр Чаллы шәһәре Хакименә җибәрү өчен исемлеккә кертүгә нигез булып тора.

## 3 бүлек. Истәлек билгесен тапшыру тәртибе

18. Истәлек билгесен тапшыру тантаналы шартларда шәһәр Хакиме тарафыннан гамәлгә ашырыла. Шәһәр Хакиме йөкләмәсе буенча һәм аның исеменнән Истәлек билгесен муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе, Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органарының башка вазыйфаи затлары тапшырырга хокуклы.

19. Истәлек билгесен тапшыру 2026 елның 2 февраленнән 2027 елның 1 февраленә кадәр башкарыла.

## 4 бүлек. Истәлек билгесенең тасвирламасы

20. Истәлек билгесе диаметры 60 мм, калынлыгы 3,6 мм булган түгәрәк формага ия һәм алтынга охшаш металл белән капланган, күп төсле эмальле җиз-никель эретмәсеннән тора.


21. Истәлек билгесенең алгы ягында, үзәктә – Яр Чаллы шәһәре гербының төсле сурәте (халык депутатларының Яр Чаллы Шәһәр Советының 2005 елның 17 мартындагы 2 номерлы карары белән расланган), әйләнә буенча диаметры 46 мм булган кант белән рамкаланган. Чаллы (27 мм* 24 мм) 34 мм – зәңгәрсу төстәге күк йөзе, 12 мм — күкне аерып торучы ак төстәге дулкынлы су фонында урнашкан. Билгенең әйләнәсе буенча ак фонда язулар: өстә – «ЯР ЧАЛЛЫ» (3,5 мм), аста – «НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ» (3,5 мм), сулда – «400 лет», уңда – «400 ел». «Лет» һәм «ел» сүзләренең биеклеге 2 мм, «400» саннары - «4» цифры 3,5 мм һәм «00» цифрлары 2 мм. Өстәге һәм астагы язулар лалә чәчәге сурәте, нокта белән башлана, нокта, лалә чәчәге белән тәмамлана.

Истәлек билгесенең арткы ягында, үзәктә – Яр Чаллы шәһәренең 400 еллыгы эмблемасы (эмблема урнаштырылган фон алгы ягына охшаш: 34 мм - зәңгәрсу төстәге күк йөзе, 12 мм – күкне аерып торучы ак төстәге дулкынлы су), ул әйләнә буенча диаметры 46 мм булган кант белән рамкаланган. 400 еллыкның эмблемасы түбәндәгеләрдән гыйбарәт: «4» цифры (23 мм * 12 мм), уртада кисешкән түгәрәк формасындагы ике «0» цифры (15 мм* 28 мм), «00» цифрлары астында «1626-2026» (4 мм * 23 мм) даталары урнашкан. Медаль кырыеннан «400» санына кадәр 15 мм. Истәлек билгесенең әйләнәсе

буенча ак фонда — язулар: өстә – «ЯР ЧАЛЛЫ» (3,5 мм), аста – «Набережные Челны» (3,5 мм), сулда – «400 лет», уңда – «400 ел». Өстә һәм аста язылган сүзләр лалә чәчәге сурәте, нокта белән башлана, нокта, лалә чәчәге белән тәмамлана.

Барлык сурәтләр рельефлы.

22. Истәлек билгесенең график сурәте:




23. Истәлек билгесе куе кызыл төстәге флок белән тышланган футлярга урнаштырылган. Тартманың нигезе акка буялган катыргыдан тора. Капкачы — үтә күренмәле пластик. Билге өчен ложементның зурлыгы — 60 мм.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

И.А. Сәгыйдуллина

«Яр Чаллы шәһәренә 400 ел»
юбилей истәлек билгесе турында
нигезләмәгә кушымта

Яр Чаллы шәһәре Хакиме

______________________________

Яр Чаллы шәһәренең 400 еллыгын бәйрәм итү уңаеннан
«Яр Чаллы шәһәренә 400 ел» юбилей истәлек билгесен тапшыру турында
ЮЛЛАМА

Юбилей истәлек билгесен тапшыру турында юлламаны хуплавыгызны сорыйм

______________________________________________________________

Гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме__________________________

Вазыйфасы, эш урыны ____________________________________________

Гражданлыгы ___________________________________________________

Билге тапшыруга тәкъдим ителә торган гражданның конкрет казанышлары күрсәтелгән характеристика

______________________________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| Юридик зат<br>җитәкчесенең вазыйфасы | имза | Ф.И.А.и. |

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2026 елның 28 гыйнварындагы
М 22 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәренә 400 ел» юбилей истәлек билгесен тапшыру турында юлламаларны карап тикшерү буенча комиссия составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | | Вазыйфасы |
|---|---|---|---|
| 1. | Сәгыйдуллина И.А. | - | комиссия рәисе, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары |
| 2. | Әхмәтова Г.К. | - | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе |
| 3. | Гаделшина Р.Р. | - | комиссия секретаре, Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе башлыгы |
| комиссия әгъзалары: | | | |
| 4. | Әхмәтҗанов Л.И. | - | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы |
| 5. | Батюшов А.М. | - | Шәһәр Советының мәгариф, мәдәният, милли мәсьәләләр, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиясе рәисе, Татарстан Республикасы Журналистлар берлегенең Яр Чаллы шәһәрендәге бүлеге рәисе (килешү буенча) |
| 6. | Кропотова Н.А. | - | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 7. | Мулюкова С.Р. | - | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы |
| 8. | Сәетова З.Н. | - | «Яр Чаллы шәһәренең ветераннар (пенсионерлар) берләшмәсе» җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| 9. | Сәлимханов И.А. | - | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 10. | Фәттахов М.Ә. | - | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 11. | Хәбибуллин Ф.Ф. | - | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. | Харисов В.Х. | - | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 13. | Хөснуллин А.Ш. | - | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

И.А. Сәгыйдуллина